СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018елның 28 декабре Әгерҗе шәһәре № 33-2

Җәмәгать тыңлаулары, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 октябрендәге 387-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук Әгерҗе районы прокуратурасының 2018 елның 22 ноябрендәге 02-01-18-2018 номерлы мәгълүматын карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 27 июнендәге 28-2 номерлы карары белән расланган җәмәгать тыңлаулар, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 1.2 пунктның сигезенче абзацында «яисә муниципаль берәмлек башлыгы» сүзләрен», муниципаль берәмлек башлыгы яисә үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;
1.2. 4.1 пунктта «яки район башлыгы» сүзләрен ", район башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе,» сүзләренә алмаштырырга;
1.3.5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5.1. Халык яки район Советы инициативасы буенча үткәрелгән җәмәгать тыңлаулар район Советы тарафыннан билгеләнә, ә район башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча - район башлыгы тарафыннан билгеләнә.»

2.Әлеге карарны PRAVO.TATARSTAN.RU Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе В.В. МАКАРОВ